ГЛАВА
БОЛЬШЕТИГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Зур Тигәнәле авылы **КАРАР**

**02.12.2021** **№ 7**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Әшнәк
авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Уставы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегенең Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап 2021 елның 16 декабренә график нигезендә билгеләргә (Кушымта).

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Зур Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (сатып алу, күчереп йөртү, вак таш салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- Әшнәк авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьларын, исәпкә алу приборларын, таймерларны, СИП чыбыкларын сатып алу, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);

- җәйге чорда (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) территорияне каралту һәм үләнне чабу;

- каты көнкүреш калдыклары җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру һәм контейнерлар сатып алу (төзелеш материалы сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартнамә буенча);

- су манарасы өчен насослар сатып алу;

- тракторны карап тоту һәм ремонтлау (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Зур Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук «Ошняк» кибете бинасында Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Әшнәк авылы, Х.Вахит урамы, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы** **Н.Ө.Хаметшин**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ - БОЛЬШЕТИГАНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р 05 11124/13
СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Алексеевский
муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл
җирлеге башлыгының 02.12.2021 № 7
карарына кушымта

# ГРАФИК
## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендә Әшнәк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын этаплап үткәрү

| **№ п/п** | **Үткәрү датасы** | **Үткәрү вакыты** | **Үткәрү урыны** | **Искәрмә** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 16.12.2021 | 9:00 сәг. | Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасы. Адрес: Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 йорт | Гагарин урамы М.Җәлил урамы |
| 2 | 16.12.2021 | 11:00 сәг. | Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасы. Адрес: Зур Тигәнәле авылы, А.Баттал урамы, 17 йорт | Х.Вахит урамы |